ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОАКСУБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКСУБАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА АКСУБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Центральная, д.31,
с.Новое Аксубаево, 423070

Үзек урам,31 енче йорт
Яңа Аксубай авылы , 4203070

Тел.: (84344) 4-20-47, факс: (84344) 4-20-47. E-mail:Naks.Aks@tatar.ru ,
http://aksubayevo.tatarstan.ru

# КАРАР

№ 4

2021 елның 21 мае

Яна Аксубай авыл җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2018 елның 24 декабрендәге 11 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында,Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Яна Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яна Аксубай авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яна Аксубай авыл җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 24 декабрендәге 11 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (3 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5. пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган белешмә (өземтә) астында түбәндәгеләр аңлана: хуҗалык кенәгәсеннән өземтә, йорт кенәгәсеннән архив өземтәсе, алдагы яшәү урыныннан белешмә»;

1.2. 2.5. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бирүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне раслаучы документ;

2) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ, гариза бирүче вәкиленең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш);

3) гариза:

- кәгазь йөрткечтә документ формадасында (1нче кушымта);

- «Электрон култамга турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә имзаланган гариза (тиешле мәгълүматларны интерактив формага кертү юлы белән тутырыла);

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү кирәк булган, һәм федераль закон нигезендә мондый шәхси мәгълүматларны эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән башкарылган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән затның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгын алуны раслаучы документлар тапшыра. Рөхсәт алуны раслаучы документлар, шул исәптән, электрон документ формасында да тапшырылырга мөмкин;
5) йорт кенәгәсен саклау бурычы 2017 елның 31 декабренә кадәр торак биналарның милекчеләренә йөкләнгән булса, гариза бирүче тарафыннан йорт кенәгәсе тапшырыла;
6) шәхси торак йортка хокук билгели торган документлар (әгәр милек хокукы Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса) - хуҗалык кенәгәсеннән өземтә өчен.
Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.
Гариза һәм кушып бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазь йөрткечләрдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:
- шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат);
- почта аша.
Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан Республика порталы аша электрон документлар рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.».
1.3. 1 нче кушымтаны кушымта итеп бирелә торган редакциядә бәян итәргә.
1.4. 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яна Аксубай авыл җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 2021 елның 14 апрелендәге 3 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://Aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә. һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яна Аксубай авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: А.В.Макаров

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яна Аксубай авыл җирлеге Башкарма комитетының
2021 елның 21 мае 4 номерлы карарына кушымта
1 нче кушымта

_______________________________
(муниципаль берәмлек җирле
үзидарә органы исеме)

_______________________________

_______________(алга таба-
гариза бирүче).
(фамилиясе, исеме, атасының исеме,
паспорт мәгълүматлары,
яшәү урыны буенча теркәлү, телефон)

Белешмә ( өземтә) бирү турында
ГАРИЗА

Белешмә (өземтә) бирүегезне сорыйм ______________________________.
(белешмә төрен күрсәтергә)
Адрес буенча:_____________________________________________________

Гаризага түбәндәге документларны терким:
1. ______________________________________________________________
2. ______________________________________________________________
3. ______________________________________________________________
_________________________________________________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында түбәндәге ысул
белән хәбәр итүегезне сорыйм: ___________________________________

_________________/___________________/____________________________
(дата) (имза) (Ф.И.А.)